## СУКЫРЛАР ЙОРТЫ

*– Калдыр мине! Ник килдең артымнан? Әнә юлың, кит каршымнан!*

*Кыз һаман кардай ак эшләпәсен тирле кулларында йомарлады.*

*Ир-егет йөзен диңгез ягына борып, сигаретын сизелер-сизелмәс кенә калтыранган иреннәренең очына гына кыстырып ут элдерде дә, кулын зажигалкасы белән бергә яртылаш кесәсенә яшерде. Кыз сүрән генә тавыш белән сөйләвен дәвам итте:*

*– Мәхәббәт күзләрем беркемне танымый. Хәер, мин ул күзләремне әле дөньяга ачканым да юк кебек. Ник?.. Кызык сорау…*

*Кыз эшләпәсен тагын күпергән чәчләре өстенә каплады. Егет күзләрен диңгез өстеннән алмый гына көлемсерәп куйды.*

*Кыз тагын очкынлы карашларын егетнең хәрәкәтсез йөзенә сирпеп алды да, чүгәләп, эшләпәле башын тезләренә терәде…*

*Шушы искиткеч матур парның шәрә аякларына бәргәләнә-бәргәләнә, күбекле дулкыннарын икесенең дә йөзләренә чәчрәтә-сибә, диңгез ярсыды…*

*– Син аңларсыңмы мине?*

*Кыз, башын артка ташлап, күз карашларын әллә кайдагы ераклыкка төбәде дә, туктап уйларынмы, сүзләренме барлады.*

*Иңнәренә кагылып киткәндә, кызның диңгез җилендә күшеккән җилкәләренең салкынлыгын тоеп, егет сискәнеп куйды.*

*– Нинди төсләр мине бәхетлерәк итәр? Мәхәббәтнең төсе нинди? Өметемне шул төскә буйый-*

*сым килә! Мәхәббәт күзләрем сукыр бит минем. Тәңремнән сорыйм, күрсәт, кайда соң минем сөйгәнем димен? Ак томан арасыннан шәүлә генә уза. Һич таный алмыйм, кем соң ул? Тазамы ул, зәгыйфьме, чистамы ул, керлеме? Шушы тар юлдан алга барам да барам. Юлым озын инде, бик озын, тик буш. Чык тамчысыннан карашларын барлыйм, салкын җилләрдә җылы сулышын тотмакчы булам, бөтерелеп аккан болытлар аңа табан әйдиләр, ак томан арасында аның эзләре бар сыман... Кем ул? Кайда ул, көтәме ул мине?..*

Инде искереп, саргаеп беткән китапның бу тетелеп беткән битләрен Рәхилә еш алып укыды. Ул аны дулкынландырды, хисләндерде. Һәм укыган саен соңгы җөмләсенең үзгәргәнен көтте. «Алар йөз ел бергәләшеп рәхәтләнеп яшәделәр» дигән җөмлә белән тәмамлануын көтте. Җөмлә үзгәрмәде. Әллә ничә тапкыр кулына ручка алып үзе өстәп тә куясы килгән иде, тиешле сүзләр тапмады. Язган кешенең каләме нечкә, хисләре өрфиядәй иде. Бәлки, башкача укып карарга кирәктер? Бу хикәягә башка күзләр белән карар өчен, күңеленә, бәлки, бүтән күзлек кияргә кирәктер? Юк-юк, сукырлар гына кия күзлекне. Аңа күзлек кирәкми! Аңа бер генә тамчы яктылык кирәк иде.

Хәмит, авыр сулап, утырган җиреннән торды да ачык калган келәт ишеген барып бикләде. Аннары өй эчен тагын бер кат карап чыкты – кытыршы стеналарга кулларын тидерде, ишек яңакларын капшаштырды, өелеп торган буяу савытларын читкәрәк этеп куйды.

– Хәмит, әйдә кайтыйк, хәлем юк.

Хатынының авыр гына сөйләгән сүзеннән ул сискәнеп китте.

– Кыярларга су сипмибезмени?

– Юк!

– Ник?

– Ашыйсылары килсә, килеп сибәрләр.

Хәмит кулына тоткан балта сабын баскыч астына этеп җибәрде дә, авыр карашларын тагын хатыны-

на күтәрде. «Яраттым микән мин бу кешене?» – дип уйлады кинәт ир. Хатыны да авыру газабы сеңгән ялварулы күзләрен Хәмитенең ябык йөзләренә текәгән килеш хәрәкәтсез калып ниләрдер уйлый иде:

«Берәр яхшылык эшлисе иде дә үзенә, хәлемнән килмәс. Бигрәк нык ябыгып та киткән икән үзе, бичара ир».

«Кара ничек бетерешкән, кечерәеп калган, ямьсезләнгән ул», – дип уйлады Хәмит. «Киемнәре дә нык керләнгән икән», – дип фикер йөртте хатыны, ирен беренче күргәндәй, аның киемнәренә текәлеп. «Кара, соңгы арада ничек ямьсезләнгән ул, – дип уйлады һаман Хәмит. – Яшь чакта матур иде сымак». «Ташласа, авыр булыр инде. Тик авыру хатын карап яшәве читендер», дип авыр сулап, дымланган керфекләрен аска төшерде хатын.

Хәмит хатынына тагын да батырыбрак карады. Аның йөзендә күзенә әләрлек бер генә мәхәббәтле җирен табасы килде. Яшисе бар бит! «Ничек шул авыруын күрмәскә өйрәнергә икән?» – дип уйлады ир, әллә нигә ике учы белән дә күкрәк турысын угалап.

– Әйдә кайтыйк, Хәмит.

Хатын урындык яурынына тотынып урыныннан торды да иренә борылып карамый гына ишеккә юнәлде.

– Сатыйк дисез инде, алайса?

Хәмитнең урыныннан кузгаласы килмәде. Әгәр монда яшәп китсәләр, киләчәге бәхетлерәк булырдай кебек иде бит. Ул ике бүлмәле фатирда үзләреннән башка бүген-иртәгә өйләнергә торган малае, ике баласы белән иреннән аерылып кайткан кызы яшиләр. Шул борылырга да урыны булмаган, диванга утырып телевизор карарга да урын тар җирдә гомере буе кулыннан төшмәгән балтасыннан башка, такта, юынган агач, пычкы чүбе исеннән башка тагын ничек яшәп була?

Күнеп китәр, әлбәттә. Күнәр! Хатыны авыру бит. Авыруга сылтасаң, ул да сәламәт түгел. Шәһәр фатирында яши алмау чире белән авырый. Ник аның да бу авыруын исәпкә алмыйлар?

Балаларга акча кирәк! Балаларга аерым фатир сатып алыр өчен өй саткан акча кирәк. Хатынының авыруы бер сылтау гына. Йомшак күңелле атаның күңеленә икеләнә алмаслык ясап сеңдерелгән сылтау. Хәмит моны белә.

Иң кызганычы — хатыны да нәкъ ире кебек уйлый, тик ул да балаларының басымына каршы тора алырлык көчтән мәхрүм иде.

— Ярар, — диде Хәмит, тәрәзә каршына басып, хатынына борылып карамый гына. — Бар кайт. Мин бүген монда кунам.

Хатыны кинәт борылып нидер әйтмәкче булды, тик ире, кискен бүлдереп:

— Калам дигәч калам. Иртәгә иртүк кайтырмын, борчылма, — диде һәм шуның белән сүз бетте дигәндәй, тыгып куйган җиреннән балтасын үрелеп алып, йортка юнәлде.

— Рәхилә!

Капкадан чыгып баручы хатын иренең тавышыннан сискәнеп китте.

— Рәхилә! Үпкәләмә миңа. Кичер, — диде Хәмит, әллә яшерен уйларыннан, әллә аның үзен генә кайтарып җибәрүеннән кыенсынып.

Хатыны Хәмитнең нәрсә әйтергә теләгәнен аңлапмы-аңламыйммы, күз чите белән генә иренә карап торды да салмак хәрәкәтләр белән капкадан чыкты.

«И улым, — диде аңа берзаман күрше Хәйбибрахман бабасы. — Менә Хәсбикамал әбиең ничәмә еллар инде түшәк өстендә, үзе дә интегә, миңа да җиңел түгел. Сиңа сер итеп кенә әйтәм, бик авыр булды миңа әбиең белән гомер итүе. Бик көйсез, холыксыз иде. Балаларыбыз булмады, шуңадыр да, бәлки. Бик түзалмаслык авыр чакларында Аллаһыга: «Мин әзер, ике куллап риза-бәхил, җанымны бүгеннән ала аласың», — дип ялвардым. Аллаһым бу килешүгә ризалашмады. Алай да булмагач, «Түзәр әмәлем юк, түшәгендә ятып та җанымны корыта, икебезнең беребезне бер-бер хәл кыл» дип ялвардым. Аллаһы җавап бирмәде. Көннәрнең берсендә, төнге намаздан соң миңа җавап килде. Шушы үтенечләрем өчен оялырлык аңлату иде ул. Хәсбикамалым минем, үлчәвемнең

икенче башы — үлчәү ташы, ахирәттә хисап көнендә мине яклап таныклык бирергә тиешле җан иясе икән бит. Мине яклап! Хәзер һәр намазымда шушы ялгышым өчен Аллаһымның кичерүен сорыйм».

Еш искә төшерде Хәмит күрше бабасының бу гыйбарәсен. Авыр сулап, ара-тирә чеметкәләп торган күкрәк турысын ышкыган чакларында гел хәтеренә килде. Һәм түзде.

Хатыны кайтып киткәннән соң, Хәмит, әллә ни эшлисе эшләре бар кеше кебек, балтасын күтәреп әрлебирле йөренде, аны-моны эшләп карады, тик һичнәрсәгә күңеле ятмады. Аннары, төшке аштан калган вак-төяк ризыкны җыеп алып чыгып, бакча уртасында учак ягып җибәрде.

Бар бакчаны каплап, учактан аксыл төтен күтәрелде. Чатыр-чотыр янган агач пүләннәре тирә-юньгә йолдызлы чаткыларын сипте. Кинәт күңелендә әллә кайдан, яшь чагында хисләнеп-хисләнеп җырларга яраткан җыры калыкты. Онытылмаган икән, йөрәгенең бер күрегендә генә яшеренеп яткан ласа:

Йолдызлардан йолдыз атылганда,
Очрашканда көннәр төн белән,
Бу дөньяны буйдан-буйга гизеп,
Синең барлыгыңны мин беләм.

«Синең барлыгыңны мин беләм», — дип пышылдап көйләп куйды да, утка күзләрен текәп туктап калды. Шул көйләүдән кинәт аның күңеле колач җитмәслек булып киңәйде һәм анда яшьлегенең кар-буранлы кышлары, исерткеч шомырт исе аңкыган язлары, йолдызлары җиргә яткан кара төнле җәйләре, бәхет чуарлаган көзләре терелеп кайнаша башлады.

Хәмит, шушы төннең аулаклыгына, беркем комачауламый, рәхәтләнеп бер истәлекләренә бирелеп утыра алуына куанып, тагын күзләрен четердәп янган учакка текәде.

Кем яши иде соң аның яшерен-татлы мәхәббәт илендә?

Илгизәсе!

Илгизә-ә-ә!